БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 03 2026 ел № 124

Балтач муниципаль районы составына кергән авыл җирлекләре территориясендә яшәүче гражданнар өчен торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлык эксперт-консультация советының 2026 елның 18 гыйнварендагы 6 номерлы хаты һәм торак комиссиясенең 2025 елның 25 февралендәге 3 номерлы карары нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү өчен торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен 36 406 сум күләмендә кулланырга.

2. Балтач район башкарма комитетының «Торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында» 2025 елның 22 февралендәге 95 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов